УДК 297

*З.Р. Хәбибуллина*

# СӘЯХӘТЛӘР АНТРОПОЛОГИЯСЕ ОБЪЕКТЫ БУЛАРАК УРАЛ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ХАҖ СӘФӘРЕ

В статье с позиций антропологии путешествия рассматривается феномен религиозного паломничества. Главным и незабываемым путешествием, предписанным Кораном, для мусульманина является хадж, или паломничество в Мекку. Несмотря на обязательность хаджа как пятого столпа ислама, верующие считают его путешествием в земном и сакральном пространствах. Для большинства мусульман мира он представляет собой преодоление определенного пути и связан с разного рода трудностями, теологически – это ряд церемоний, которые должны быть выполнены в определенных священных местах. В центре нашего внимания – паломничество мусульман Южного Урала, его место и роль в жизни мусульманского населения региона. На основе полевых материалов, полученных в работе с паломниками, представителями Хадж-миссии России, духовенством и верующими, рассмотрены мотивы, поведенческие схемы современных паломников, культурное значение хаджа, факторы, оказывающие влияние на развитие паломнической традиции местных мусульман.

**Ключевые слова:** антропология, паломничество, путешествие, ислам, хадж, Мекка, Медина, Урал

Сәяхәтләр антропологиясе – илебезнең тарих фәнендә әле яңа юнәлеш, ул дөньяның глобальләшүе һәм XXI гасырда туризмның гадәттән тыш киң таралуы нәтиҗәсендә актуальләшә. Бу юнәлеш хәрәкәт итүнең күптөрлелеген һәм аның эзлекле эшчәнлек схемасы һәм вакыйгалар барышына бәйле эш-гамәлләргә ярашлы рәвештә барлыкка килгән механизмнарын өйрәнүгә нигезләнә. Социаль төркемнәрнең хәрәкәтен тикшереп өйрәнү иҗтимагый аңны һәм ачыкланып җитмәгән уй-фикерләрне (хәрәкәт мотивларын, карар кылу механизмнарын, акция һәм реакцияләрнең үзара нисбәтен) танып белүгә юл ача [Головнев, с. 10]. Кеше сәяхәткә билгеле бер мотивлар белән һәм нәрсәне дә булса күреп өйрәнүне күздә тотып чыга.

Географик «сәяхәтләр» ландшафт төрлелеген күреп белүгә юнәлдерелә һәм ул ландшафттан, шәхси һәм әһәмиятле уртак нокталарга ия когнитив киңлекләрдән чыгып билгеләнә [Наука странствия…]. Бу билгеләмәгә хаҗ кылу да керә, ул сәфәр кылучыларга изгелек ландшафтына төшенергә ярдәм итә. Бүгенге дөньяда борынгыдан килгән изге урыннарга күмәкләп зиярәт кылу йоласы активлашты һәм ул массакүләм мәдәни күренешкә әверелде. Яңа (XVII гасырдан башлап) һәм Иң яңа заманнарда фәннең көчле үсеш алуы һәм дөнья турында фәнни карашлар йогынтысында традицион дини-мәдәни ландшафтны

юкка чыгарырга омтылу процессы дини йола-тәртипләрнең мөһим бер компоненты саналган хаҗ кылу гадәтен туктата алмады. Изге урыннарга күмәкләп сәфәр кылу, дини функцияләрдән тыш, экзистенциаль пространство формалаштыруда һәм аны билгеле (ягъни аерым кешеләр яки төркемнәр күңелендә тамырланган, әмма аларның һәркайсы өчен генә хас булган мәгънәгә ия) калыпка салуның җитди ысулына әйләнә бара [Замятин, с. 3].

Изге урыннарга сәфәр кылу бөтен диннәрдә бар, исламда ул аерым әһәмияткә ия. Хаҗ кылу һәр мөселман өчен Аллаһ карашындагы фарыз гамәлләрнең бишенчесе (соңгысы) булып санала. Хаҗ сәфәре, исламда мәҗбүри үтәлергә тиешле төп бурычтан тыш, исламның дөньякүләм үсешенә йогынты ясау функциясен дә үти: ул мөселманнарда үз диннәренең тиңсез кодрәтенә инану ихтыяҗын канәгатьләндерә, бу диндәгеләрнең бердәмлеген тормышка ашыру механизмын тәшкил итә. Мөселманнарның ел саен, дөньяның барлык кыйтгаларыннан да килеп, изге Мәккәдә очрашуы аларның рухи, мәдәни элемтәләрен, психологик бердәмлеген, ислам берлегенең социаль тупланганлыгын ныгыта. Исламда чиркәү институтлары да, катгый мәгънәдәге руханилык та юк, шуңа күрә Мәккәгә хаҗ кылуның берләштерү роле көчәя һәм ул мөселманнарның дөньяви өммәтен (җәмгыятен) символлаштыра һәм гәүдәләндерә.

Хаҗ кылуның Мөхәммәд һәм Коръәнгә исеме теркәлгән башка персонажлар тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле төп объектлары Согыд Гарәбстаны Корольлегенең Хиҗаз өлкәсендәге изге шәһәрләрендә урнашкан: Мәккәдә – изге «кара таш» урнаштырылган Кәгъбә, шәһәр читендә Сафа һәм Мәрвә калкулыклары, изге «Зәм-зәм» чишмәсе, Гарәфәт үзәнлегендә Муздалиф җирлеге; Мәдинәдә – Мөхәммәд пәйгамбәр, аның кызы Фатыйма, изге Әбү Бәкер, Гомәр, Госман хәлифәләрнең, Мөхәммәднең хатыны Гайшәнең каберләре, Мөхәммәд мәчете (Пәйгамбәр мәчете). Бу өлкәнең территориясенә туристларга һәм башка диндәгеләргә керү тыела, болардан тыш мөселманнарның үзләренә дә (вакытлы, урынга бәйле, догматик күрсәтмәләре, визасы булмаганнарга) чикләүләр билгеләнгән.

Хиҗазга бару хаҗ кылган очракта гына рөхсәт ителә, бу таләп изге шәһәрләргә нинди дә булса эш белән баручыларга карата да куела. Россиядән хаҗ кылырга баручыларны озатып йөрүче дин эшлеклеләре, табиблар, гидлар, хаҗ миссиясе һәм турагентлык вәкилләре һ.б. барысы да, үз вазифаларыннан тыш, хаҗ кылырга тырышалар. Хиҗазда табынуның ике варианты кулланыла: зур хаҗ (яки хаҗ) кытгый бер вакыт кысаларында – ай календареның уникенче ае – зөлхиҗҗәдә; кече хаҗ (өмрә хаҗы) Мәккәдә елның (зур хаҗ көннәреннән кала) теләсә кайсы вакытындда уздырыла. Кече хаҗның йолалары зур хаҗныкыннан аерылмаса да, дин тотучылар өчен аның әһәмияте бик үк югары булмый.

Шәригать кануннары нигезендә хаҗ сәфәренә чыгу өчен мөселманга түбәндәге таләпләр куелган: балигъ булу; үз акылында булу; азат булу (кол түгел); талау, үтерү һ.б. кебек тыелган гамәлләр үтәргә мәҗбүр ителмәү; үз сәфәренә һәм өйдә калган гаилә әгъзаларын матди тәэмин итәргә, хуҗалыкны алып барырга җитәрлек акчасы булу; сау-сәламәт булу; юлда үзенең иминлеген сакларга сәләтле булу. Шулай ук зөлхиҗҗә ае башында тиешле йолаларны үти башлау өчен хаҗ сәфәренә алданрак чыгу да мөһим [Керимов, с. 100–102]. Шәригатьтә матди мөмкинлеге чикләнгән булса һәм сәламәтлеге зәгыйфь булса (ягъни үзенең тормышын куркыныч астына куеп) хаҗ сәфәренә чыгу тыела. Әмма, шундый таләпләр куелуга карамастан, мөселманнар Мәккәгә омтылалар. Бер генә илдә дә кешеләргә хаҗ кылу өчен чикләүләр закон нигезендә каралмаган. Руханилар дин тотучыларга «хаҗ кылу – ул байлар өчен, ярлыларга мәчеткә йөрү дә җитә. Әгәр бай кеше хаҗда булмаса, ул, үлгәч, динсезләр рәтендә саналачак», дип аңлаталар [АЭМ, Уфа, 2013].

Россиядә хаҗ кылу мөселман динен тотучылар йоласы булып санала, дәүләт белән мөселман җәмгыяте арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең мөһим элементын тәшкил итә. Бүгенге заман мөселманнарының хаҗ кылу йоласын өйрәнү проблемасы, 1990 еллардан башлап хаҗга баручылар санының артуы сәбәпле, аерым әһәмияткә ия. Согыд Гарәбстаны корольлеге тарафыннан мөселманнар яши торган илләргә карата билгеләнгән норма – 1 мең мөселманга бер кеше. 2009 елдан башлап Россиядән Согыд Гарәбстанына ел саен хаҗ кыларга 20500 чамасы мөселман бара. Ә безнең ил өчен квота күләме 20 мең. Хаҗ сәфәрен оештыручылар советы мәгълүматлары буенча ел саен анда барырга теләүчеләрнең 3–4 меңенә (чынлыкта бу сан күпкә артык) хаҗга бару өчен юллама җитми кала [Ильяс Умаханов…].

Россиядә ислам бербөтен социомәдәми бердәмлек тәшкил итми, тикшеренүчеләр аның социаль, мәдәни, психологик үзенчәлекле төзелешкә ия берничә ареалын аерып күрсәтәләр. Алар – Төньяк Кавказ, Идел буе, Урал һәм Көнбатыш Себер. Мәкаләдә Көньяк Уралда яшәүче мөселманнарның Согыд Гарәбстанындагы изге өлкә – Хаҗазга сәфәре үзенчәлекләре анализлана, анда баручыларның составы, мотивлары һәм бүгенге мөселман хаҗиларының үз-үзен тотыш формалары тасвирлана. Күпконфессияле Көньяк Урал регионында ислам факторын өйрәнү кысаларында РФАнең Уфа фәнни үзәге тарафыннан Башкортстан Республикасы (Аскын, Балтач, Белорецк, Бүздәк, Бөрҗән, Караидел, Зианчура, Туймазы, Уфа районнары) буйлап, шулай ук Оренбург өлкәсенә (Оренбург шәһәре), Курган өлкәсенә (Сафакүл, Әлмәт, Щучан районнары) оештырылган экспедицияләр вакытында безгә хаҗилар белән очрашып әңгәмәләшергә дә туры килде. Хаҗ кылу йоласын өйрәнүдә төп игътибарны аның

субъектына – җәмгыятьтәге теге яки бу катламга караган, дөнья турында билгеле бер карашка, тәртипкә һәм шәхси психологик үзенчәлекләргә ия булган кешегә юнәлтү мөһим [Калужникова]. Андый шәхесләр белән әңгәмәләр һәр кешегә хас каршылыклы эмоцияләр һәм кабул итүләр белән дә очрашырга мөмкинлек бирә.

Көньяк Уралда ислам йолаларын татарлар, башкортлар һәм казаклар үти. Башкортстан Республикасында хәзер барлык халыкның 53,8% ын этник мөселманнар тәшкил итә, Оренбург өлкәсендә бу күрсәткеч – 17%, Чиләбе өлкәсендә – 13,3%, Курган өлкәсендә – 6% [Всероссийская…]. Регионда, традицион исламны торгызу белән беррәттән, мөселманнарның социомәдәни дәрәҗәсе түбән булу, исламда «авыл» һәм «шәһәр» аерымлыкларының тотрыклы саклануы, руханилар һәм аларның җитәкчеләрнең дәүләткә таянуы, икътисади яктан тулы бәйсезлек булмау бүгенге көндә мөселманнарның хаҗ кылу активлыгы сүлпән булуда чагылыш таба [Юнусова]. Төньяк Кавказ һәм Татарстан Республикасы белән чагыштырганда, Мәккәгә хаҗ сәфәре кылу Уралда бик үк популяр түгел. Гомумроссия масштабыннан чыгып караганда хаҗиларның иң күп саны Дагстанга туры килә (80%), гәрчә илдә мөселманнар саны ягыннан зур күпчелекне татарлар һәм башкортлар тәшкил итсә дә (53%) [Нуриманов, с. 73]. Бу күренеш билгеле бер дәрәҗәдә икътисади кыенлыклар белән бәйле: Урал мөселманнарына хаҗга барып барлык йолаларны да үтәп кайту өчен 200 мең – 400 мең сум акча кирәк. Әмма Уралдагы хәйриячеләрнең матди ярдәме Төньяк кавказлыларныкы масштабында түгел. Чечен Республикасы башлыгы Р. Кадыйров белән Дагстан Республикасыннан сенатор С. Кәримов ел саен әз керемле 5–6 мең мөселманга хаҗ сәфәре кылу өчен хәйрияви юлламалар өләшәләр.

Төньяк Кавказда мөселманнар өчен биш фарыз гамәлнең соңгысын үтәүнең югары дәрәҗәдә булуы бу территориядә исламның үзенчәлекләре, аны торгызуның темплары зур булу һәм бу регионның географик яктан Согыд Гарәбстанына якын урнашуы белән аңлатыла. Хаҗ кылу йоласын үтәүнең бүгенге торышын регионнарда ислам үсешенең интенсивлыгы билгеле, ә ул алардагы социаль-икътисади күтәрелеш дәрәҗәсе, халыкның хезмәт белән мәшгульлек сферасы өстенлеге, таралып урнашу формалары һәм социотабигый җайлашу кебек фактларга бәйле [Галләмов, с. 77]. Идел–Урал регионы мөселманнары Россиянең Европа өлешендә һәрвакыт исламның үзенчәлекле аванпостында булдылар, андагы гади дин тотучылар ислам илләрендәге мәдәният һәм көнкүреш белән якыннан таныш булмадылар.

Согыд Гарәбстанының хаҗ кылу урыннары Көньяк Уралга бик ерак, шуңа да карамастан, биредәге мөселманнар, ислам урнашканнан башлап, анда барып хаҗ кылырга омтылып яшиләр. Элек хаҗ кылып кайту вакыты,

ярты елдан башлап, берничә елларга сузыла торган булган, нигездә аны дини эшлеклеләр һәм бай мөселманнар гына үтәгән. Совет чорында хаҗга баручылар исәбе катгый регламентлаштырыла (бөтен илдән 20–30 кеше) һәм анда сәфәр кылучылар куркынычсызлык органнары тарафыннан сайланып, тикшерү үтәләр [Мухаметзянова-Дуггал, с. 53]. Хәзер хаҗ сәфәре кылу бик кыйммәткә төшә. 2013 елда, мәсәлән, «стандарт» программасы буенча ул 4200 доллар тәшкил итте [Рисалят, с. 12], 2014 елда мәчетләрдә таратылган мәгълүмати буклетларда 5500 доллар күрсәтелгән иде. Шәригать нигезендә бу максат өчен акчаны намус белән хезмәт итеп тупларга кирәк. Мөселманнар хаҗ сәфәренә юлга чыкканчы бер ел алдан әзерләнә башлыйлар: кирәкле документларны җыялар, прививка ясаталар, Диния нәзарәтләре каршында рөхсәт (виза) эшләтәләр. Урал хаҗилары һава транспортыннан файдалана, аларның Хиҗазга сәяхәте 25–30 көн дәвам итә. Гомумән алганда хаҗилар саны арту күзәтелә. 2007 елдан башлап, мәсәлән, Башкортстаннан Мәккәгә ел саен 300–400 дин тотучы бара, ә 2001 елда бу күрсәткеч 42 генә булган.

Хәзерге Россия дәүләте хаҗ сәфәрен оештыруда эчке һәм халыкара уңайлы шартлар тудырырга тырыша. Моның өчен Россиянең барлык регионнарында да дәүләти, административ, матди-техник, финанс, халыкара һәм кадрлар ресурслары, дәүләттән тыш иҗтимагый һәм дини потенциаллар җәлеп ителә. 1990 елларда хаҗ сәфәре билгеле бер тәртип буенча оештырылмый, ул чынлап та зур түземлелеккә сынау чарасы була: берничә көн авиарейслар көтеп утыру, алданулар, түләнгән юлламалар һәм хәтта турфирмалар юкка чыгу, Согыд Гарәбстаны корольлеге тарафыннан аз керемле мөселманнарга дип җибәрелгән юлламаларны сату кебек хилафлыклар еш кабатлана. Россиядән хаҗга баручы төркемнәр таркау хәрәкәт итә, кешеләр, соңга калган ватандашларын көтеп яки кунакханәгә урнашу өчен бронь булмау сәбәпле, берничәшәр көн дәвамында тукланмыйча автобусларда көн уздыралар; сәяхәтчеләрнең төп массасына медицина ярдәме бөтенләй күрсәтелми, яисә ул вазифаны хаҗилар арасындагы медицина белеменә ия кешеләр үти [Сахаутдинов, с. 21]. Хәзер хаҗилар идентификацияләнгән электрон беләзекләр белән тәэмин ителә, ул, кирәге чыкканда, аларның кайсы урында булуларын ачыкларга ярдәм итә. Шулай ук 1990 елларда хаҗилар составын һәм санын бик тикшереп тормыйлар, анда теләүчеләрнең барысы да диярлек бара иде. Соңгы елларда Диния нәзарәтләре илгә бирелгән квотадан, совет чорында хаҗ кылу чикләнгән булу сәбәпле, иң элек өлкән яшьтәге мөселманнарга өстенлек бирәләр.

Хаҗның мәҗбүри йола таләпләре булуга карамастан, мөселманнар бу сәфәрне тормышка ашыру вакытында үзләренең шәхси мотивларына таянып эш итәләр. Ул мотивлар дөньяви

һәм рухани-дини хаҗиларны аерырга ярдәм итәләр. Дини хаҗилар өчен хаҗ кылу исламның фарыз гамәлләренең берсен үтәү булып санала, аларның андагы вакытлары һәм матди чыгымнары диннәренә инануларын тулы чагылдыра. Хиҗазга сәяхәт аларга рухи чистарыну һәм тормышларын өр-яңадан башлау мөмкинлеге бирә. Дөньяви хаҗилар исә хаҗга үзләре өчен исламның асылын ачу, табыш алу яки сәяси мәнфәгатьләрен күздә тотып баралар. Хаҗ кылу кеше тормышының хәлиткеч мизгеленә әйләнергә мөмкин, күпчелек очракта ул ортодоксальлек ягына үзгәрә. Бу тенденция интеллигентлар өчен характерлы.

1990 елларда хаҗ кылу республикалар башлыклары арасында популярлашты. Мәсәлән, президент булганчы ук М. Шәймиев (Татарстан), М. Рәхимов (Башкортстан), А. Кадыйров (Чечен Республикасы) хаҗ сәфәре кылдылар. Федерация субъектлары белән халыкка һәм туган илгә тугрылык антын Коръән тотып биргән президентт-хаҗилар идарә итте. Ислам руханилары «дәүләт һәм хөкүмәт җитәкчеләре Ходайдан куркалар икән, аларга ышанып була, алласызлар янәшәсендә беркайчан да тәртип булмаячак», дип фикер йөртәләр [АЭМ, с. Зигибяк, 2014].

Дөньяви һәм дини мотивларның кисешүе дә күзәтелә, бу күренеш аеруча дини эшлеклеләр арасында еш очрый. Бу төркем дини йолаларны тулырак саклый. Дингә ышанучылар даирәсендә хаҗ кылу Аллаһтан куркуны, иманга тугрылыкны раслый. Мөселман җәмгыяте җитәкчесе вазифасына билгеләгәндә яки аны сайлап куйганда хаҗда булып кайтучыларга өстенлек бирелә.

Мотивлар төркемнәрдәге мөселманнарның яшьләре белән дә аерыла: яшьләр өчен хаҗ кылу мәгърифәтлелек (дини яктан белемлелек) функциясен үти, өлкән буын исә бу сәфәргә гөнаһларыннан арыну, Аллаһ нигъмәтләрен үз күзләре белән күреп кайту нияте белән чыга. Көньяк Урал регионындагы яшьләр һәм мул тормышлы мөселманнар үзләрен әле хаҗ кылырга әзер түгел дип саныйлар, алар бу гамәлне рухи үсешнең иң югары этабы буларак бәялиләр.

Физик яктан да, рухи яктан да шактый авыр саналган хаҗ сәфәрендә мөселман хатын-кызлар да актив катнаша, алар хәтта күпчелекне тәшкил итә. Хәзер хаҗияләр саны арту дәвам итә, алар арасында хаҗ кылуга зур омтылыш саклана. Хатын-кызлар төрле юллар белән Мәккәдә булырга тырышалар. Хаҗ кылу тарихыннан мәгълүм булганча, XX гасыр ахырларына кадәр күп төрле катлаулылыклар белән бәйле бу сәфәргә нигездә ир-ат чыккан. Ислам мәхрәмнән (өйләнешү тыелган якын кардәштән) башка хатын-кызга сәфәр кылуны тыя, әмма 45 яшь тулганнан соң андый чикләү бетерелә. Әлеге яшькә җитмәгән хатын-кызлар төркеме хаҗ сәфәренә дини идарә вәкиле җитәкчелегендә юл ала.

1990 еллар башында күп кенә хатын-кызлар, дини йолалар үтәү белән бергә, үзләренең юл чыгымнарын каплау өчен, аннан

дини атрибутлар, кием-салым, келәм, алтын эшләнмәләр алып кайтып, сату белән шөгыльләнделәр. Хәзер дә хаҗ сәфәрен табыш алу максатында кулланучы хатын-кызлар бар, алар нигездә эшсезләр һәм пенсия яшендәгеләр. Югары белемгә ия һәм уңышлы эшмәкәрлек итүче яки дәрәҗәле урында эшләүче хатын-кызлар арасыннан да хаҗ кылучылар саны арта бара. Мәккәгә берничә мәртәбә (4–5 тапкыр) барган хатын-кызлар бар. Алар анда беренче тапкыр булганнан соң, курортларда ял итүгә караганда, акча җыеп яңадан Согыд Гарәбстанына барырга тырышалар [АЭМ, г. Уфа, 2013].

Хатын-кыз хаҗияләр саны арту, беренче чиратта, хаҗ сәфәре шартларының үзгәрүе белән бәйле, хәзер анда хезмәт күрсәтүләр туристларныкы дәрәҗәсендә, Мәккәгә бару да кыенлык тудырмый. Уралдагы динилек вазгыяте илкүләм хәлдә чагылыш таба, Россиядә хатын-кызлар чиркәүләргә һәм башка гыйбадәтханәләренә күбрәк йөриләр һәм дини йолаларны бирелеп үтиләр. Көньяк Уралда да ислам таләпләрен үтәүчеләрнең төп өлеше хатын-кызлар, аларның күбесе шәригать кануннарын катгый үтиләр, шуңа күрә хаҗга баралар.

Хаҗ кылучы хатын-кызлар артуның төп нәтиҗәсе дип мөселман хатын-кызларның үз-үзен тотышында яңа стереотиплар һәм җәмгыятьтә аларны кабул итү нормалары формалашуны атарга була. Хатын-кызларда башка илләрдәге мөселман хатын-кызлары белән уртаклыклар барлыкка килә, аларның дингә инануларын арттыра, аларга исламның уңай якларын (әйтик, яулык бәйләү, ябык кием кию) табарга ярдәм итә. Алар башта ислам йолалары символларын дин белән бәйле модага ияреп кенә үтәгән булсалар, хаҗ сәфәреннән соң аларны чын күңелләреннән эшлиләр. Мөселман хатын-кызлардан бу хакта сораштырганда, аларның күбесе хаҗ кылулары турында күз яшьләре белән сөйлиләр. Хатын-кызлар, ир-атлардан аермалы буларак, хаҗ сәфәреннән һәрчак зур рухлану алалар, ир-ат исә хаҗ кылу шартларын аек акыл белән кичерә һәм күңелсез хәлләрне дә исендә калдыра. Мөселман ир-атлар хаҗ вакытында кайбер хатын-кызларның озатучысыз йөрүеннән, кайткач сатарга дип әйбер җыюыннан, «үз-үзләрен бәйсез тотуыннан, үзләренә карата кирәгеннән артык игътибар таләп итүләреннән, башка ир-атлар белән аралашуларыннан, хатын-кызларга кагылмаган проблемалар турындагы сөйләшүләрдә катнашуларыннан» һ.б.дан ризасызлык күрсәтәләр [Сахаутдинов, с. 23–24, 27]. «Исламның бөтен яңалыгы (Мөхәммәднең сүзләренә һәм гамәлләренә каршы килә торган чаралары һәм гамәлләре) хатын-кыздан», – диләр алар [АЭМ, с. Караидель, 2013]. Шул ук вакытта алар хатын-кызларның түземлелеген һәм үзара оешканлыгын да билгеләп үтәләр.

Дин тотучылар бергәлеге эчендә хаҗилар элита өлешен тәшкил итәләр һәм үзләренең бергәлегендә алар иҗтимагый климат формалаштыруга нәтиҗә-

ле йогынты ясыйлар. Хаҗ кылган кеше «хаҗи» яки «хаҗия» (хаҗ кылучы) дигән мактаулы исем ала, диндәшләренең хөрмәтенә лаек була. Аның әйләнәсендә «аеруча тәкъва кеше» нуры барлыкка килә. Мөселман кешесенә хаҗ вакытында туплаган рухи тәҗрибәсенең дини мәхәлләдә җитди кабул ителүенә шикләнергә кирәкми. Хаҗ кылу мөселман җәмгыятендә хатын-кызларның статусын да күтәрә. Хаҗи яки хаҗия белән очрашканда хатын-кызларга, мәчеткә кергәндәге кебек, яулык бәйләү гадәткә кергән; мәхәлләдә җитди карарлар кабул иткәндә хаҗияләрнең дә фикере исәпкә алына [АЭМ, с. Карткисәк, 2013]. Башкортстан Республикасының район үзәкләрендәге һәм авыллардагы мәктәп музейларында махсус бизәлешле стендларда соңгы елларда хаҗга барган авылдашлары хакында мәгълүмат урнаштырылагн [АЭМ, Зианчуринский р-н…, 2013]. Дин тотучы, әмма хаҗга барырга мөмкинлеге булмаган кешеләр хаҗи, хаҗияләр белән аралашырга омтылалар: Хаҗга баручыларны озату һәм каршылау йолаларында катнашып, юлаучыга хәер бирәләр; кайтучылар бүләк иткән изге Зәм-зәм коесы суыннан авыз итәләр. Алар өчен хаҗ кылып кайткан кешегә кагылу да зур бәхет санала [АЭМ, г. Оренбург, 2009].

Хаҗда булып кайтучылар белән әңгәмәләрдән аңлашылганча, нинди генә уңайсызлыклар, кыенлыклар кичерүләренә карамастан, аларның күбесенең хаҗ сәфәреннән тирән рухи канәгатьләнү хисләре белән кайтуларын тоясың. Мәккәгә барып ирешүгә алар үзләрен оҗмахтагыдай хис итәләр. Хәзер хаҗ сәфәрләре оешкан төстә уздырыла, дөньяви һәм сакраль пространстволар бердәмлеге күзәтелә. Мөселманнарга үзләренең төрле максатларын (коммерция шөгыле, башка илләрдән килгән диндәшләре белән аралашу, мөселман мәдәнияте белән танышу) тормышка ашыру мөмкинлеге бар. Дин тотучылар хаҗда исламча яшәү рәвеше белән танышалар. Көньяк Уралдан һәм Россиянең башка регионнарыннан хаҗга баручылар саны арту илдәге мөселманнарның ислам белән тирәннән кызыксынуын, мөселман йолаларының искеләрен торгызуын һәм яңаларын формалаштыруын дәлилли. Сәяхәт вакытында региональ тәңгәллек көчәя, мөселманнар изге җиргә Россиянең төрле почмакларыннан килеп төшәләр. Анда булучылар Мәккәдә яшәүче гарәпләрнең, кызганычка каршы, Россия мөселманнарының Кавказдан һәм Татарстаннан килүчеләрен генә белүләрен, Урал регионы (Башкортстанны да кертеп) алар өчен таныш булмавын искәртәләр [АЭМ, с. Балтачево 2013].

Хаҗ кылганда чит мәдәният белән танышу, аның белән турыдан-туры очрашу һәм үзеңнекенә читтән карау сәяхәтчегә уртак якларны баетырга ярдәм итә [Белоруссова, с. 5]. Хаҗ дин тотучыларга идеалдагы исламның асылын аңлау, күзәтүләрен һәм хисләрен үзләре яшәгән төбәкләргә алып кайту мөмкинлеге бирә. Хаҗ кылуның торган

саен киңрәк колач ала баруы Россия мөселманнарының дөнья күләмендәге гомумислам бергәлеге процессына кушылуының котылгысызлыгын раслый, ул Согыд Гарәбстаны, Төркия, Мисыр кебек эре ислам үзәкләренең Россия мөселманнарына йогынтысы астында бара. Хаҗ халыклар арасындагы туганлык элемтәләрен ныгыта, ислам мәдәниятенә һәм цивилизациясенә якынаерга этәргеч бирә. Россиядәге, шул исәптән Көньяк Уралдагы, мөселман халыкларның «Мөселман өммәте» төшенчәсенә хас булган бердәмлеккә, тупланганлыкка омтылышы көчәя бара. «Хаҗга бөтен мөселманнар да барса иде, әгәр анда бара алсам, мин иң бәхетле кеше булыр идем», – диде миңа бер дин тотучы [АЭМ, Уфа, 2013].

## Чыганаклар

АЭМ (авторның экспедиция материаллары), Оренбург өлкәсе. Оренбург шәһ., 2009.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Аскын районы Карткисәк ав., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Балтач районы Балтач ав., 2013

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Уфа шәһ., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Зианчура районы Исәнгол ав., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Караидел районы Караидел ав., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Туймазы районы, Җегетәк ав., 2014.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Уфа шәһ., Уфадагы Беренче җәмигъ мәчете, 2013.

Всероссийская перепись населения // Официальный сайт Госкомстата Российской Федерации. URL: http://perepis2002.ru

Рисалят (религиозно-просветительская газета). 2013. № 6 (179).

*Сахаутдинов В.Г.* Воспоминание о паломничестве. Уфа: МРО Ихлас, 1997. 36 с.

## Әдәбият

*Белоруссова С.* Антропология путешествия (южноевропейские путешественники XV века). Saarbruken: Lambert, 2013. 143 с.

*Галлямов Р.Р.* Исламское возрождение в Волго-Уральском макрорегионе: сравнительный анализ моделей Башкортостана и Татарстана // Ислам от Каспия до Урала: макрорегиональный подход: сб. статей / под ред. К. Мацузато. М.: Росспэн, 2007. С. 71–117.

*Головнев А.В.* Антропология движения (древности Северной Евразии). Екатеринбург: Волот, 2009. 496 с.

*Замятин Д.Н.* Феномен паломничества: географические образы и экзистенциональное пространство // Феномен паломничества в религиях: священная цель, священный путь, священные реликвии: материалы XIII Санкт-Петербургских религиоведческих чтений. СПб.: Акционер и К°, 2006. С. 3–4.

Ильяс Умаханов о хадже 2011 года. ИД «Медина». URL: http://www.idmedina.ru/books/history_culture/74748 (дата обращения: 20.02.2017)

*Калужникова Е.А.* Паломничество как ритуал: сущность и культурно-исторические типы: дис. ... канд. культурологии. Гуманитарный университет, Екатеринбург, 2007. 167 с.

*Керимов Г.М.* Шариат: закон жизни мусульман. Ответы Шариата на проблемы современности. СПб.: Диля, 2012. 512 с.

*Мухаметзянова-Дуггал Р.М., Хабибуллина З.Р.* Россия и Индия: государственное регулирование хаджа // Азия и Африка сегодня. 2011. № 1. С. 53–56.

Наука странствий: корни и перспективы. Учение о путешествиях обречено на возникновение. Интервью с В. Каганским // Частный корреспондент. 2013. 23 апр. URL: http://www.chaskor.ru/article/nauka_stranstvij_korni_i_perspektivy_31878 (дата обращения 25.11.2017)

*Нуриманов И.* Хадж мусульман России. Из прошлого к настоящему // Хадж российских мусульман: сборник путевых заметок о хадже. Нижний Новгород: ИД Медина, 2008. С. 67–79.

*Юнусова А.Б.* Ислам в России // Россия и мусульманский мир. 2010. № 6. URL: http://www.promreview.net/moskva/islam-v-rossii?page=0,6 (дата обращения: 15.12.2017).

***Хәбибуллина Зилә Рәшит кызы,***
*Россия Фәннәр академиясенең Уфа фәнни үзәге*
*Р.Г. Кузеев исем. Этнологик тикшеренүләр институты*
*дин белеме бүлеге фәнни хезмәткәре*
*E-mail: zilyahabibi@mail.ru*